**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында гражданнар җыены карары**

18 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән ветераннар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, хәрби хезмәт узу турында контракт төзүчеләрдән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелүчеләрдән тыш.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

- Тимбай авылы территориясен төзекләндерү, (җәйге чорда үләннәрне чабу, кышкы чорда карны чистарту, ягулык, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү , урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау(лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урамнарны яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү).

3. Җыен нәтиҗәләрен Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында авылында авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Тимбай авыл җирлеге башлыгы _________ И.Г.Айзатуллин

Гражданнар җыены секретаре _________ Г.А.Хәкимова